Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

# Ислам нуры

№ 10 (638) 19 май, 2017 ел (1438, Шәгъбан) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

## Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның Рамазан ае башлану уңаеннан котлавы



Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ! Мөхтәрәм дин кардәшләребез! Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән изге Рамазан ае башлану белән ихластан котлыйм!

Мөхтәрәм җәмәгать, барчабызга мәгълүм, исламның биш баганасы бар. Биш багана ул: Аллаһка һәм Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәләмгә шаһитлык китерү; намаз уку; зәкят бирү; хаҗ кылу һәм ураза тоту. Рамазан аенда менә шушы биш багананың берсен үтәргә, ягъни ураза тотарга мөмкинлек бирелгән.

Коръәндә әйтелгән: “Ий, иман китергән бәндәләр, сездән алда килеп-киткәннәргә фарыз ителгән кебек, ураза тоту сезгә дә фарыз кылынды. Бәлки, сез шаять тәкъва булырсыз?” (Коръән. Бәкарә сүрәсе, 183 аять).

Пәйгамбәребез салләлаһү гәләйһи вә сәлләм хәдисендә язылган. “Аллаһ: «Адәм углының эшләгән һәр хәерле эше үзе өчен һәм ул уннан алып җитмеш тапкырга кадәр артыр. Ураза бары тик минем өчен генә. Аның савабын да мин бирермен», — дип әмер итте”.

Без Рамазан дәвамында уразалар тотып, гөнаһларыбызны кичерүне сорап догалар кылабыз. Рамазан аенда иман белән һәм савапка ирешүгә өмет баглап, ураза токкан кешенең элеккеге барча гөнаһлары да ярлыканыр, иншАллаһ. Раббыбыз, догаларыбызны кабуллардан кылса иде!

Рамазан безне мәрхәмәтле, игелекле булырга өйрәтә, күңелләребезне тәрбияли. Сөекле Пәйгамбәребез салләлаһү гәләйһи вә сәлләм кисәтә: “Кем Рамазанда алдауны һәм ялган шаһитлык итүне дәвам итә — юкка ризыктан һәм судан тыелып тора”. Рамазан ул — начар гамәлләрдән котылу, холкыбызны яхшырту һәм авыр гөнаһлардан арыну өчен мөмкинлек. Тагын бер хәдис шул хакта ачык аңлатып бирә: “Ашау-эчүдән тыелу гына ураза тоту түгел. Бәлки яман сүздән, әшәке нәфестән тыелу — чын ураза. Әгәр бер кеше сине сүксә, син әйт: “Мин - руза”, -диген”. Хәтта яман сүз әйтсәләр дә, яман сүз белән җавап кайтарма.

Быел безнең җирлектә яшәүчеләргә уразаны 20 сәгатьләп тотарга туры килә. Хәдисләрдән мәгълүм булганча, фәрештәләр ураза тотучыларның гөнаһларын кичерүне сорап догалар кыла. Алла боерса, безнең ураза тотучы мөселманнарга догалар күбрәк тә ирешер, алар бит дөньяның башка җирләрендә яшәүчеләргә караганда уразаны озаграк тота. Монда да Раббыбызның бер хикмәте бар.

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә токкан уразаларыбызны, кылган гамәл-гыйбадәтләребезне кабул итсен, үзенең рәхим-шәфкатеннән ташламасын иде. Аллаһ исемен зикер итеп, күңелләребез белән бары Коръәнгә, иманга ашкынып үткән Рамазан ае савапларын күрергә язсын. Рамазан ае мөбарәк булсын!

**Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин.**

## Изге Рамазан аебыз мөбарәк булсын!



Мәрхәмәтле, Рәхимле Аллаһ исеме белән!

Мөхтәрәм дин кардәшләр!

Сезне Изге Коръән иңә башлаган иң кадерле аебыз Рамазан Шәрифкә аяк басуыбыз белән ихлас күңелдән тәбрик итәм! Рамазан — ураза һәм өстәмә гыйбадәтләр ае. Бу айда без Аллаһының чиксез рәхмәтләренә һәм хикмәтләренә гаҗәпләнеп туймыйбыз. Рамазанда безгә тәүлек әйләнәсендә гыйбадәт кылу, төрле изгелекләр эшләү мөмкинчелеге бирелә. Көн яктылыгында ашаудан, эчүдән тыелып тору — ул гыйбадәт. Сәхәр ашау, авыз ачу — ул гыйбадәт. Хәтта хәдистә килгәнчә, ураза тотучының йокысы да — ул гыйбадәт. Шулай булгач ураза — Аллаһыга кылган гыйбадәтләребезнең иң мөһимнәреннән берсе. Рамазанда кылган изгелекләребезгә савапларны Аллаһы Тәгалә башка айларга караганда арттырып бирә.

Аллаһы Тәгалә безгә Рамазан ае уразасы хакында болай дип җиткерә: “Ий, иман китергәннәр! Сездән әүвәлгеләргә фарыз ителгәне кеби, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде. Шаять, уразаны калдырудан яки уразага кимчелек китерүдән сакланырсыз.” (2-183). Аллаһның һәр әмерендәге кебек уразада да безнең тәнебез һәм рухыбыз өчен зур файда бар. Шуңа күрә дә Рамазан уразасы үзен мөселман дип санаган, бәлигълык яшенә җиткән, үз акылында булган, сәламәтлеге мөмкинлек биргән һәркайсыбыз өчен мәҗбүри гамәл булып тора.

Рамазан ае быел да кызу, озын көннәргә туры килә. Ошбу изге гамәлне үтәүдә зур сабырлык, күндәмлелек күрсәтүчеләр генә Аллаһы Тәгаләнең вәгъдә иткән бүләкләренә өметләнә алалар. Раббыбыз Аллаһ әйтә: “Чынлап та, сабырларга исәпсез-хисапсыз әҗерләр бирелер” (39:10.) Аллаһы ярдәменә, Аның бүләкләренә булган өметебез безгә бу сынауны уңышлы үтәргә мөмкинлек бирә. Үткән еллар тәҗрибәсе шуны ачык күрсәтте.

Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) киң билгеле хәдисендә болай диелә: “Рамазан ае керү белән Җәннәт ишекләре ачыла, тәмуг ишекләре ябыла, ә шайтаннар богаулап куела.”

Ошбу айда Аллаһы Тәгалә кылган изгелекләребезгә әҗер-савапларны дистәләрчә, йөзләрчә мәртәбә арттыра, гөнаһларыбызны гафу итә. Рамазан тәкъвалыгыбызны сынау, рухыбызны һәм тәнебезне савыктыру өчен менә дигән форсат, дин тотучылар өчен зур бүләк. Рамазан ул — дөньяга алданмыйча ахирәткә әзерләнү, рух, калебне ныгыту мәктәбе. Тәкъва мөселманнар бу айда Коръәнне башка айлардан күбрәк укый, аятьләрнең тирән мәгънәләре хакында ешрак уйлана, алардан үзенә күп файда ала.

Уразага ният итүче үзен ашау-эчүдән, җенси мөнәсәбәттән, дарулар кулланудан, тәмәке тартудан гына түгел, ә бәлки начар уйлардан, начар сүзләрдән, гайбәт сөйләүдән тыеп тора. Аллаһы Тәгалә авыруларга, юлда булучыларга мәрхәмәт күрсәтеп әйтә ки: “Сездән кем Рамазан аена килеп җитә, аны уразада үткәрсен. Әгәр ул чирле яки сәфәрдә булса, ул вакытта калдырылган көннәрне башка вакытта тотар. Аллаһ сезгә җиңеллек тели, авырлык теләми.” (2 — 185). Йөкле хатын-кызлар, бала имезүче аналар, ураза үзләренең һәм балаларының сәламәтлегенә зыян китерә дип курыкса, аны казага калдырып башка көннәрдә икенче Рамазанга кадәр тотып бетерә. Хатын-кызларга айлыклары вакытында, бала тудырганнан соң кан килү чорында ураза тоту тыела. Алар да аны казага калдырып икенче вакытта тоталар. Терелүгә өметсез авырулар, ураза тота алмаслык олы яшьтәгеләр һәр ураза көне өчен фидия садакасы түли. Быел ул нәзарәт Пленумы карар иткәнчә, һәр көн өчен 200 сум күләмендә билгеләнде. Фитыр садакасы күләме — 100 — 600 сум (зәкят түләүчеләр өчен 600 сум). 2017 елга зәкят нисабы күләме — 198000 сум.

Рамазан — юмартлык, рәхимлелек ае. Аллаһы Рәсүле кешеләр арасында иң юмарты иде. Һәм Рамазан аенда аның бу юмартлыгы тагын да арта торган булды. Әйдәгез, бу айда садакаларыбыз белән мескен-фәкыйрьләрне сөендерик, туганнарыбызның, ата-аналарыбызның хәлен ешрак белик. Берничә йөз сумнан малыбыз кимемәс, ә менә мохтаҗларны, ятимнәрнең күңелен күтәрә алырбыз.

Рамазан мөселманнар бердәмлеген ныгыта, баен-ярлысын якынайта, байларга ярлылар хәлен ныграк аңларга ярдәм итә.

Аллаһының рәхмәте белән, быел Рамазан аена 26 июнь кичендә керәбез. Бу кичтә беренче тәрәвих. Ул мәчетләрдә 20 рәкәгать укыла. Беренче сәхәр — 27 май иртәсендә. Ураза бәйрәме — 25 июньдә.

Рамазан аен тулы акылыбызда сәламәт килеш тыныч күңел белән каршыласак иде. Аллаһы Тәгалә булган мохтаҗлыгыбызга күрә һәрберебезгә Үзенең ярдәмнәрен ирештерсен һәм туры юлыннан барырга иман көче, тәкъвалык бирсен!

**Әлфәс хәзрәт Гайфуллин,**
**ҮДО - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте**
**Президиумы әгъзасы, Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе.**

# Гафу итү — олуг сыйфат

Бүген, хөрмәтле дин кардәшләрем, бер олуг, бөек сыйфат турында сөйлисем килә. Ул холыкны, сыйфатны булдырган кешегә Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең күп аятьләрендә зур әҗерләр вәгъдә итә һәм ул сыйфатны үзебездә булдырырга өнди. Нинди сыйфат соң ул? Ул - кешеләрне кичерү, үч алмау, хаталарын оныту. Әйдәгез әле, Коръән аятьләрендә, Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләрендә тукталып, уйланып алыйк.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә гафу итүчеләрне, кешеләрне кичерүчеләрне - яхшылык эшләүчеләр дип атады. Аллаһы Тәгалә әйтте: "Гафу ит аларны, әй, Мөхәммәд, һәм аларга карата киң күңелле бул, алар сиңа начарлык эшләсәләр дә, син аларны кичер, дөреслектә, Аллаһ яхшылык кылучыларны ярата" (13).

Икенче бер аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә: "Әгәр сез гафу итсәгез, үч алудан туктыйсыз икән, Аллаһы Тәгалә Гафу итүче, рәхимле, ягъни Аллаһы Тәгалә сезне гафу итәчәк һәм сезгә карата рәхимле, шәфкатьле булачак,"- дип вәгъдә итте (14).

Шулай ук Аллаһы Тәгалә әйтә: "Ә кем гафу итсә һәм араларын төзәтсә, аның әҗерен Аллаһ Үзе генә белгән кадәр бирәчәк" (40). Димәк, рәнҗетелгән, ләкин гафу иткән кешегә бик зур әҗер биреләчәк.

Шулай ук, мөхтәрәм дин кардәшләрем, гафу итү җәннәткә керүгә бер сәбәп булып тора. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтте: "Ашыгыгыз, әй мөэминнәр, Раббыгызның мәгъфирәтенә һәм җәннәткә. Ул җәннәтнең киңлеге күкләр белән җирләр арасында булган киңлек шикелле, һәм ул җәннәт Аллаһка тәкъва булган бәндәләргә әзерләнеп куелган. Алар, ягъни җәннәткә керүче бәндәләр, җиңеллек килгәндә дә, авырлыклар вакытында да сәдака бирәләр, ачулары килгәндә, ачуларын йоталар һәм аларны рәнҗеткән кешене гафу итәләр. Ә Аллаһ шундый сыйфатлы, яхшылык кылучы мөэминнәрне сөя, ярата" (133-134).

Фудәйл ибну Ияд исемле галим шулай дип әйтте: "Әгәр синең яныңа берәр кеше килеп икенче кешегә зарлана башласа, син аңа : "Гафу ит аны,"- дип җавап бир. Һәм ул: "Юк! Минем йөрәгем түзми, мин аны кичерә алмыйм, минем аннан үч аласым килә!"- дип әйтсә (чөнки бит Аллаһы Тәгалә безгә золым эшләгән кешеләрдән үч алырга рөхсәт итте), аңа: " Әгәр син ул үчеңне алганда чикләрне узмыйча ала аласың икән, ал, ә юк икән, гафу ит!"- дип җавап бир дип әйтте. Аның бу сүзләрендә бик зур хикмәт бар, җәмәгать, чөнки күбебез: "Мин бит үз хакымны гына алам, ул мине кимсетте, рәнҗетте, ә хәзер мин дә аны шулай ук рәнҗетәчәкмен,"- дип әйтәбез. Ләкин, кызганычка каршы, без, үч алганда чикләрне уза башлыйбыз, золымлык кылабыз һәм ахыр чиктә, гөнаһка эләгәбез.

Әйе, дин кардәшләрем, гафу итү, кичерү җиңел эш түгел, ләкин без тырышырга һәм Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорарга тиешбез.

Карагыз әле, җәмәгать, Пәйгамбәребез (с.г.в.) дусты Әбү Бәкер Әссыддык исемле зур сәхәбә, ничек иттереп Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсынып, кызы Гайшәгә (р.г.) тел-теш тидергән, аны зиначы дип яла яккан кешене гафу итә, кичерә.

Мистах ибну Әсәсә исемле сәхәбә бик фәкыйрь иде һәм Әбү Бәкернең якыны иде. Һәм Әбү Бәкер аңа сәдака итеп акча бирә иде. Шуннан монафикълар Мәдинәдә анабыз Гайшә турында зиначы дигән хәбәр тарата башлыйлар. Һәм шушы Мистах ибну Әсәсә исемле сәхәбә монафикъларның сүзләрен тыңлап, шул кабахәт сүз турында сөйләшә башлады. Һәм Әбү Бәкер, ул сәхәбәнең монафикъларны тыңламау урынына, алар белән кушылып сөйләшкәнен белгәч, ул аңа сәдака бирмим дип ант итә. һәм барыбыз да, җәмәгать, Әбү Бәкер урынында булсак, шулай ук итәр идек, хәтта әле теге кеше янына килеп, бәлки, кыйнар идек.

Шуннан соң Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) аять иңде. Ул аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтте: "Сезнең арагыздан бай булган кешеләр, әй, мөселманнар, туганнарына, мескеннәргә һәм мохтаҗларга акча бирмим дип ант итмәсеннәр, алар гафу итсеннәр һәм хаталарны кичерсеннәр! Әллә сез Аллаһы Тәгаләнең гафу итүен теләмисезме? Аллаһ бит ул Гафу итүче, рәхимле,"- дигән аять иңгәч, Әбү Бәкер: "Әлбәттә, Аллаһ белән ант итәм, мин Аллаһы Тәгаләнең гафуын телим,"- ди һәм Мистах ибну Әсәсәгә яңадан акча бирә башлый. Һәм ул әйтә: "Аллаһ белән ант итәм, мин бүтән беркайчан да акча бирүдән туктамыйм,"- ди.

Гафу итү, кешеләрнең хаталарны кичерү - ул Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) һәм аңа ияргән сәхәбәләрнең сыйфатыдыр. Анабыз Гайшәдән Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) холкы, әхлагы турында сорагач, ул әйтте: "Ул бозык, ямьсез, кирәкмәгән сүзләр һәм эшләр кылмый иде, һәм базарлардагы кебек кычкырып торучы түгел иде, һәм шулай ук аңа берәрсе начарлык эшләсә, ул үч алмый иде, ә гафу итә, хаталарын кичерә иде,"- ди.

Һичшиксез, гафу итү, кичерү җиңел эш түгел, кешенең яман нәфесе аңа әйтә башлый: "Ничек инде син аны гафу итәсең? Ул бит сиңа шулай-шулай эшләде, бу бит зәгыйфьлек, көчсезлек була түгелме соң?" Нәфесне тыңларга кирәкми! Киресенчә, гафу итү, гафу итә алу - ул кешенең көчле икәнлеген күрсәтә. Аның гыйззәтен, данын күтәрә. Һәм бу Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсыну була. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: "Аллаһы Тәгалә гафу итүче колның гыйззәтен, данын арттырыр. Дөньяда да, ахирәттә дә кадерен, дәрәҗәсен күтәрер."

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә: "Явызлык, золым эшләүчегә үзе золым иткән хәтле генә җәза бирелә, ә кем ул явызлык эшләгән кешене гафу итсә, һәм аның белән дуслашса, ул кешенең әҗерен Аллаһы Тәгалә Үзе бирер. Дөреслектә, Аллаһ арттырып үч алучыларны яратмый" (40).

Димәк, бу аятьтә без өч төрле кешеләрне күрәбез:

— беренчесе — ул уртача дәрәҗәле кешеләр. Ул кешедән аңа начарлык эшләгән хәтле генә үч ала, арттырмый да, киметми дә.

— икенчесе - түбән дәрәҗәле кеше. Ул золымлык белән, арттырып үч ала.

— өченчесе - ул иң бөек дәрәҗәле кеше. Ул - гафу итүче, хатаны кичерүче була, һәм аңа Аллаһ әҗерен Үзе чиксез бирәчәк.

Шуңа күрә, уйланыйк, безнең шушы өч төрле кешеләрдән кайсылары рәтендә буласыбыз килә?

Кешене гафу итәсе килмәгәндә, шушы аятьләрне, хәдисләрне, Аллаһы Тәгалә вәгъдә иткән зур, хисапсыз әҗерләрне, Җәннәтне исебезгә төшерик. Ничек инде без, мөселманнар буларак, нәфесебезгә ияреп, шушы әҗерләрне калдыра алабыз?

Бу темага туры килә торган бер хәдисне исегезгә төшерергә телим. Ул Имам Әхмәт җыентыгында китерелә. Абдулла бну Гумар сөйли: "Бервакыт без Аллаһның Илчесе белән утыра идек. Ул безгә: "Хәзер монда җәннәт әһеле керәчәк,"- дип әйтте. (Сез күз алдына гына китереп карагыз, Пәйгамбәребез (с.г.в.) ул кеше исән чакта ук аның җәннәт әһеле икәнен әйтә. Нинди бөек дәрәҗә бит бу). Шуннан барыбыз да ишеккә төбәлдек. Ишектән кешеләрдән гыйбадәте белән дә, дәрәҗәсе белән дә аерылып тормаган, бик гади генә бер кеше керде. Икенче көнне дә Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Хәзер монда җәннәт әһеле керәчәк,"- дип әйтте, тагын шул кеше керде, өченче көнне дә бу хәл кабатланды. Шуннан минем бу кешенең нинди хикмәте барлыгын бик тә беләсем килде. Аннан мин өч көн мине үзендә кундыруын сорадым, ул кеше риза булды. Мин өч көн буе күзәттем ул кешене. Мин аны төннәр буе намаз укыйдыр дип уйлый идем, ә ул укырга тиешле намазлардан артыгын укымады. Шуннан мин: "Сине Пәйгамбәребез (с.г.в) җәннәт әһелләреннән дип әйтте, син бит бер дә артыгын эшләмисең, ничек соң бу болай?"- дип сорадым. Ә ул: "Мин һәр көнне кешеләргә карата чиста йөрәк белән йокларга ятам. Минем йөрәгем көнчелектән, дошмалашудан, күралмаучанлыктан, үпкә — рәнҗешләрдән чиста,"- дип җавап бирде." Шулвакыт Абдулла бну Гумар әйтә: "Менә нәрсәдә син бездән алда икәнсең, без моны булдыра алмыйбыз,"- ди.

Бу кеше урынында без дә булырга мөмкин. Йөрәгебез чиста булсын!

Кардәшем, сиңа золымлык кылучыларны кичер син, синең турыда начар сөйләүчеләргә, гаделлекнең чикләрен үтүчеләргә ачу тотма! Аларны гафу ит, кичер син аларның гаделсезлекләрен. Элек эшләгән, яки хәзер эшли торган урыныңда кешеләргә ачуың булса, гафу ит аларны. Ирең, хатының белән бергә яши алмыйча, аерылышкансыз икән, бер-берегезгә ачуланып, дошманлашып калмагыз, гафу итегез бер-берегезне. Әгәр балаларың сине үпкәләткән булса, аларны да гафу ит. Әти-әниеңә ачуың булса, аларны да кичер. Киң күңелле, кешеләрне гафу итүче бул. Тар күңелле, бәхетсезләрдән булма! Гафу ит. Сине моның өчен Аллаһы Тәгаләнең шундый зур әҗере, бүләге көтә. Аллаһы Тәгалә бит: "Ә кем гафу итсә, һәм араларын төзәтсә, аның әҗерен Аллаһ Үзе генә белгән кадәр бирәчәк,"- ди.

Нәрсә соң ул Аллаһның бүләге? Күз алдына китереп карагыз әле. Сиңа бер кешенең бик зур бурычы бар ди, ул бурычын түли алмый, шуннан икенче бер кеше килә дә, мин аның әҗәтен түлим, ди. Менә шулай Аллаһ та безгә хатыныңны, иреңне, балаңны, әти-әниеңне, күршеңне, туганыңны, коллегаңны һәм башкаларны гафу ит, ди. ГАФУ ИТ, Ә ӘҖЕРЕН ҮЗЕМ БИРӘМ, ди.

Кардәшем, күңелең киң булсын, тар күңелле булма. Тар күңелле кеше гомере буе интегә, шулай ук ул кешеләрне дә интектерә. Менә күз алдына китереп кара әле: син тормыш юлы буйлап барасың, ди. Синең кулыңда синең үпкәләрдән, рәнҗешләрдән, ачулардан торган бик авыр сумка. Еллар буе шул авыр сумкаңны күтәреп, бер туктамый барасың. Шушы сумкаңа һаман кешеләргә булган ачуларыңны җыясың. Авыр таш булып ката синең ачуларың. Инде күтәреп тә булмаслыкка әйләнә ул. Нишлисең син, кардәшем!!! Ташла син бу авыр ташыңны! Сумкаңны, җаныңны ач, алып ташла син бу авыр ташны җаныңнан!

Бервакыт Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Иң яхшы холыкны әйтимме сезгә?"- дигәч, "Әлбәттә, әйт."- диләр аңа. Ул:"Сиңа начарлык кылучыларны гафу итүче," — диде.

Бер кеше Әбү Хәнифә хәзрәтләре янына килә дә: "Синең әниең шундый-шундый,"-дип начар нәрсәләр әйтә башлый. Ул: "Аллаһ Белүче, минем әнием андый түгел,"- ди. Ә бу кеше туктый алмый, ул Әбү Хәнифәгә: "Син монафыйк,"- ди. Шуннан Әбү Хәнифә: "Йә, Аллаһ, мин шундый булсам, мине гафу ит, әгәр ул ялгышса, бу кешене гафу ит,"- дип әйтә.

Гафу итәргәме, юкмы - сезнең эш. Миңа калса, мин миңа золымлык кылучыларны, гайбәтемне сөйләүчеләрне, начарлык кылучыларның барысын да гафу итәм. Әгәр инде үлгән булсалар, аларны Аллаһның кичерүен һәм җәннәткә кертүен сорыйм. Исән булсалар, Аллаһтан аларга яхшы иман, сәламәтлек, бу дөнья һәм ахирәт нигъмәтен телим. Ни өченме? Чөнки мин моның белән уңышка ирешәм. Йөрәгемдәге ачу утын сүндерәм. Шуннан күңелләр киңәя. Яшәү җиңеләя.

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев,**
**Чаллының "Тәүбә" мәчете имам-хатыйбы.**

# Тарихыбыздан гыйбрәт алыйк

Аллага шөкер, Идел-Урал төбәгендә яшәүче мөселман өммәтебез ел саен майда Идел Буе Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми рәвештә кабул ителгән көнне зур күтәренке рух илә билгеләп үтә. Бу тарихи вакыйга 922 елда булган. Әмма ләкин тәңречелек динен тоткан борынгы ата-бабаларыбыз гарәпләр белән һәм ислам диненә дәгъвәт белән күпкә иртәрәк танышканнар. Ул дәвердәге борынгы төркиләрнең Гарәп хәлифәлеге белән беренче контактлары бик тә катлаулы булган. Хәлифәлекнең төньяк-көнчыгыш ягында, Мавераннахрның Согдиана дәүләте җирләре (хәзерге Урта Азия яклары) төрки ата-бабаларыбызның һәм гарәпләрнең үзара төрле һәм даими мөнәсәбәтләргә кергән төбәге булган. VII — VIII гасырларда Иран дәүләтен яулап алгач, гарәпләр Согдианага бәреп керәләр һәм ошбу бай, көчле илнең шәһәрләрен тиз буйсындыралар. Әмма оазислардан соң хәлифәлек экспансиясен дәвам итеп Урта Азиянең далаларына чыккач күчмә төркиләр белән очрашалар. Төркиләр сан белән ишле булмасалар да, гарәпләрне туктаталар, тәкъдим ителгән Ислам динен баш иеп, ашыгып кабул итмиләр — тәңречелектә калалар.

Шул ук елларда Тан империясе (хәзерге Кытай) хәрби көч илә Урта Азияне буйсындырырга, империянең чикләрен киңәйтергә теләгән дәвер булганын да онытмыйк. 751 елны зур кытай гаскәре Талас үзәнлегенә (хәзерге Кыргызстанның төньягы) бәреп керәләр һәм гарәп гаскәренә очрыйлар. Өч көн барган сугышта, бер як та җиңүгә ирешә алмаган чакта төрки бабаларыбыз ошбу сугышка үз өлешләрен кертәләр. Кытайның гасырлар буе төркиләрне юк итү сәясәтен үз җилкәләрендә татыган ата-бабаларыбыз Кытай гаскәренә һөҗүм итәләр һәм аларны тар-мар итүдә ярдәм итәләр.

Шул дәвердә башланган ифрат көчле мөселман дөньясының тәэсире Урта Азиянең йөзен үзгәртә. Хәтта яңа этносның барлыкка килүенә дә (ягъни этногенезиска) этәргеч була. Гарәпләрнең төрки хатыннарга өйләнгән өлеше таҗик — таҗ гаскәренең (коронные войска) барлыкка килүенә төп фактор була. Ә соңрак X гасырда Сәмәни дәүләте кысаларында гарәпләрнең, согдиана халкының, өлешчә иранлыларның һәм парфяннарның, төрле төрки кабилә вәкилләренең берләшүе нәтиҗәсендә көчле таҗик этносы барлыкка килә. Ошбу милләт фарсы телле булып формалаша. Чөнки бу төбәктә фарсы теле халыклар аралашуында зур роль уйнаган. Ә гарәпләргә төрки телне үзләштерү фарсы телгә караганда кыенрак булган дип фараз кылырга мөмкин.

Нәтиҗәдә Урта Азиянең Ислам цивилизациясенә керүе безнең борынгы Идел-Чулман якларындагы Болгар дәүләтенә дә тәэсир итә.

Хәзер инде Гарәп ярымутравының төньягына күз салыйк. VII гасырда Византия империясенә кергән Сүрия өчен башланган сугыш тора-бара Кече Азия ярымутравына һәм Кавказга барып җитә. Хәзәр дәүләте Кавказ провинцияләрен яклап гарәпләргә каршы сугышырга мәҗбүр булгач, Көнчыгыш Рум империясенең табигый союздашына әверелә. Ә хәлифәлек Хәзәр иленең Кавказ провинцияләрен үз контроленә алырга тырыша.

Ифрат күләмдә ресурслар таләп иткән бу сугыш 642 елда башланып, бер туктап, бер кабынып, 800 елларда гына тына. Бу төбәкнең төп халыклары ( хазарлар, болгарлар, аланнар, әрмәннәр һ.б.) бердәм булып гарәп экспансиясенә каршы сугышсалар да, хәлифәлек зур югалтуларга карамастан, ахырда җиңүгә ирешә.

Хәрби-стратегик әһәмияткә ия булган Дербент шәһәре гарәпләрнең көчле таяныч үзәгенә әверелә. Ә соңрак IX-X гасырларда җирле халыклар арасында Ислам динен таратуда билгеле бер мәркәзгә әверелә.

IX гасырда Хәзәр дәүләтендә яһүдиләр тора-бара сәүдә тармагын, соңрак хакимиятне дә үз кулларына алалар һәм шундук төп төрки халыкның ярдәменнән мәхрүм калалар... Читтән акчага ялланган хәрби төркемнәргә карамастан дәүләт көчсезләнә, нәтиҗәдә халкы тарала башлый.

865 елда ук христиан динен кабул иткән хәзәрләрнең бер өлеше Терек һәм Дон казаклары этногенезиясендә катнашалар. Дәүләтнең өстәге яһүди катламы төрле якка тарала, ә бер өлеше хәзерге Кавказдагы таулы яһүдиләр (горские евреи), ә төрки хатыннарга өйләнгән яһүдиләр караим этник төркеменә нигез салалар. Ә менә Ислам динен кабул иткән хәзәрләр иленең әһле - Әстерхан татарлары, ә соңрак казак халкының этногенезисендә катнашалар.

Ул дәвердә дин халыкларның барлыкка килүенә, аларның язмышларына, хәтта дәүләтләрнең язмышына ифрат зур тәэсир итә торган фактор булган.

Параллель рәвештә Гарәп хәлифәлеге VII гасырның азагында Византиягә каршы һөҗүмен көчәйтә. Шул ук вакытта — 665 елда Византиянең төньягында Дунай дәрьяының аскы агымында Аспарух хан җитәкчелегендә болгарлар бәреп кереп үзләренең дәүләтенә нигез салалар. Шул тарихи вакыйгадан башлап Константинополь Болгар дәүләтен юк итәргә тырышты. Әмма ләкин 717 елда Мәрмәр диңгезенең култыгын кичеп Византиянең пайтәхетен урап алгач, император Лев III үзенең күрше дошманнарыннан, ягъни Болгар дәүләтеннән ярдәм сорый.

Тервел хан гарәпләрне тар-мар итә һәм аларның Көнчыгыш Аурупага юнәлгән экспансиясен туктата. Ошбу зур әһәмияткә лаек булган вакыйга ике дәүләт арасындагы антогонистик мөнәсәбәтләрне юкка чыгармый һәм үзара сугышлар еш кабынып тора.

IX гасырда болгарларның өске катламы Византияне үрнәк итеп христиан динен кабул итәләр (864 елда Барис хан чукына). Ә чиркәүләрдә гыйбадәтләр, уку-язулар славян телендә алып барыла. Шуның нәтиҗәсендә славян кабиләләре белән бер дәүләттә яшәгән болгарлар төрки телен югалтып славянлашалар.

Йомгаклау: күп очракта Ислам динен кабул иткән борынгы төркиләр милли йөзен, телен, мәдәниятен, дәүләтчелеген югалтмаганнар, киресенчә, баетканнар гына. Шуңа күрә без, дин әһелләре, әүвәл милли мәнфәгатьләребезгә, туган телебезгә шәхси омтышыбызда, дини мәҗлесләрдә, йола-гыйбадәтләребездә (исем кушу, никях, җеназа), җомга вәгазьләребездә өстенлек бирергә тиеш.

Яшьләребез дини, фәлсәфи, социаль-сәяси терминологияне белмәгәнгә күрә бүтән телгә күчмичә вәгазебездә очраган ошбу җитди төшенчәләрне иренмичә тәрҗемә итеп барырга кирәк. Аның өчен эш өстәлебездә һәрдаим татар теленең аңлатмалы сүзлеге, урыс-татар һәм татар-урыс телләре сүзлекләре булырга тиеш. Безнең тел галимнәре шул юнәлештә сүзлек чыгарсалар бик яхшы булыр иде.

Мөмкинчелек булса мәктәпләребезнең ана теле кабинетларын интернетка тоташтырырга, проектор-экраннар һ.б. уку әсбапларны алып бирергә булышыйк. Ана теле укытучылары белән кулдан-кул тотынып халкыбызга хезмәт итик.

Тарихыбыздан гыйбрәт алсак, киләчәккә карап иҗтиһат илә гамәл кылсак, милләтебезнең, туган телебезнең киләчәгенә өмет белән карап яшәргә булыр, инша-Аллаһ.

**Ирек хәзрәт Хөснетдин,**
**Башкортостанның Мәләвез районы,**
**Җиргән саласының "Мәхәллә" мәчете имам-хатыйбы.**

***Хикәят***

# Хәерсез байлык

Аллаһы Тәгалә әйтә: "Алар арасында: "Әгәр Ул безгә юмартлыгыннан бирсә, әлбәттә, без садака бирербез һәм изгеләрдән булачакбыз,"- дип Аллаһ белән килешү төзегәннәр дә бар. Ә аларга Аллаһ Үзенең юмартлыгыннан биргәч, алар саранланды һәм читкә китеп йөз чөерде" (9:75-76).

Ошбу аять Сәләбә ибн Хәтимә әл Әнсарга карата төшерелә. Сәләбә көн-төн пәйгамбәребез (с.г.в.) мәчетендә була. Ягъни гаиләсендә булган вакытны исәпкә алмаганда. Шуңа күрә аны "мәчет күгәрчене" дип атыйлар. Күп мәртәбәләр сәҗдә кылудан аның мангае дөя тезенә охшап кала.

Күпмедер вакыттан соң Сәләбә мәчеттән пәйгамбәребез (с.г.в.) иртәнге намазны тәгәллләү белән тәсбихне һәм доганы көтмичә китә башлый. Моны күреп Аллаһы илчесе аңа әйтә:

— Әй, Сәләбә, сиңа нәрсә булды? Син нигә монафыйкларны кабатлый башладың?

— Әй, Аллаһның илчесе! Мин бик ярлы. Хәтта син уйлаганнан да ярлырак. Мин ошбу күлмәкне киям һәм намаз укыйм. Шул вакыт хатыным көтеп тора. Намазны тәмамлагач мин күлмәкне салам һәм хатыныма бирәм. Ул намаз укый. Әй, Аллаһның рәсүле! Миңа байлык теләп дога кылсаң иде.

— Әй, Сәләбә, бу уеңнан кайт. Син шөкер итә торган байлык күп байлыктан хәерлерәк һәм син аңа шөкер итә алмаячаксың

Күмпедер вакыт узгач Сәләбә үтенечен кабатлады. Бу юлы Аллаһ рәсүле аңа болай диде: "Син миңа охшарга тырышмыйсыңмыни? Мин шуны беләм: дөнья бәхете ахирәттән буш калучылар өчен генә. Акылы булмаган кеше генә дөнья тормышы белән алданыр."

Күпмедер вакыт узгач Сәләбә пәйгамбәребез (с.г.в.) янына кабат килде һәм әйтте: "Әй, Аллаһның илчесе, Аллаһ белән ант итәм, син миңа дога кылсаң мин малымны моңа лаек һәр кешегә таратыр идем."

Сәләбәнең бертуктаусыз үтенечләренә җавап итеп пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дип дога кылды: "Йә, Раббым Аллаһ, Сәләбәгә байлык бир!" Бу сүзләрне өч мәртәбә кабатлады.

Догадан соң Сәләбә бер сарык сатып алды. Тора-бара аның сарыклары күп булып үрчеде. Хәтта шуңа барып җитте ки: Сәләбә сарыклары Мәдинә урамына сыймый башлады. Ул көтүен көтүлеккә күчерде. Һәм шуның аркасында биш вакыт намаз укуны ташлады. Ә сарыклары тагын да күбәйде һәм аларга инде берничә көтүлек кирәк булды. Сәләбә Мәдинәдән ераклашты. Хәтта ул җомга намазына да йөрүдән туктады.

Бер көнне пәйгамбәребез (с.г.в.) сәхәбәләрдән сорады:

— Сәләбә кайда? Мин аны күрмим?

Сәхәбәләр әйттеләр:

— Әй Аллаһның илчесе! Аның малы күбәйде, ул хәзер бер көтүлеккә генә сыймый, шуңа күрә ерак көтүлекләргә китәргә мәҗбүр булды.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте:

— Сәләбәгә кайгы булсын!

Шуннан соң зәкят түләргә әмер биргән түбәндәге аять инде: "Аларның малларыннан садака ал, аларны шуның белән пакьларсың һәм сафларсың. Алар өчен дога кыл. Синең догаң алар өчен тынычлану бит" (9:103).

# Чаллы Җәмигъ мәчетендә төзелеш сезоны башлана

Чаллы Җәмигъ мәчетендә шушы көннәрдә җәйге төзелеш сезоны башлана. Быелгы сезонда мәчетнең ноль циклын (җир асты өлешен) төзеп бетеру бурычы куела. Ягъни быел 18 млн. 950 мең сумлык эш башкару ният ителә. 11 майда Чаллы мөхтәсибәтендә имам-мөхтәсиб Әлфәс хәзрәт Гайфуллин катнашында Җәмигъ мәчете төзелешенә финанс ярдәме күрсәтү фонды җитәкчесе Уел Хәсәенов һәм "Стройтраст" җәмгыяте генераль директоры Раил Миннегалиев шул хактагы килешүгә кул куйдылар. Уел Галим улы әйтүенчә, кышкы чорда төзелешкә әзерлек алып барылган, җитәрлек күләмдә арматуралар сатып алынган, төзелешкә әзерлек буенча тиешле тикшерүләр уздырылган.



**Рәсемдә:** *килешүгә кул кую вакытында*

## Ветераннарны хөрмәтләү



9 майда Чаллының "Әбүзәр" мәчетендә өйлә намазыннан соң Бөек Җиңү бәйрәме уңаеннан мәчет картларын хөрмәтләү чарасы үтте. Аның барышында мәчет имам-хатыйбы Али хәзрәт Баһаветдинов һәм имам Хәлвәтдин хәзрәт Баһаветдинов ветераннар адресына күп җылы сүзләр әйттеләр, аларга дини мәрәсимнәрне зур активлык белән башкарып килүләре өчен рәхмәт белдерделәр, исәнлек-саулык теләделәр. Чарада катнашучы мәчет аксакалларына азык-төлек җыелмасы тупланган пакетлар тапшырылды.

**Рәсемдә:** Али һәм Хәлвәтдин хәзрәтләр мәчет карталары арасында.

## Җиңү бәйрәме уңаеннан Аксакаллар мәҗлесе



Чаллы мөхтәсибәте каршындагы Аксакаллар шурасы 4 майда шәһәр мәчетләренең иң актив аксакаллары хөрмәтенә Җиңү бәйрәме уңаеннан аш мәҗлесе уздырды. Ул Аксакаллар шурасы рәисе Равил хәзрәт Нуруллин имамлык иткән "Туфан" мәчетендә узды. Мәҗлес барышында Коръән укылды, догалар кылынды, Равил хәзрәт Нуруллин, шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, төбәк казые Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев ветераннарны Җиңү бәйрәме белән кайнар котладылар, аларга исәнлек-саулык, озын гомер теләделәр. Мәҗлес ахырында Равил хәзрәт мәҗлестә катнашучыларга истәлекле бүләкләр тапшырды.



Мәҗлестә шәһәр мәчетләре имамнары, "Ак мәчет" мәдрәсәсе шәкертләре дә катнашты.

**Рәсемнәрдә:** мәҗлестән күренеш — имам-мөхтәсиб Әлфәс хәзрәт һәм Равил хәзрәт чыгыш ясыйлар.

## Аллаһы Тәгаләнең кунагы

Тагын бер хәдисен белдем
Мин пәйгамбәребезнең:
Кунагы өч төрле кеше
Аллаһы Тәгаләнең.

Беренчесе: хаҗга барган
Кеше шундый хөрмәттә.
Икенчесе: үзе теләп
Булган кеше мәчеттә.

Хәл белергә килүчеләр
Авыру-сырхауларның –
Алар була өченчесе,
Савабы бик зур аның.

Сырхау янына барганда
Дога кыла фәрештә,
Ул догалар кабул була,
Сиңа уңыш – һәр эштә.

Син мохтаҗларга булышсаң,
Ходай ача юлларың,
Проблемаларыңны чишә,
Әҗере бик зур аның.

**Асия КОРБАНГАЛИЕВА,**
**Әгерҗе шәһәре.**

* * *

Бу дөньяда Ходай биргән рәхәт тормыш:
Тәмле ашыйбыз, киенәбез затлы кием;
Кайдан килгән рәхәт тормыш,
матур язмыш –
Килгәндер ул Аллаһының
рәхмәтеннән.

Онытмыйк без ятим үскән балаларны,
Тирәбездә ялгыз калган әбиләрне,
бабайларны;
Булышыйк без ятимнәргә, мохтаҗларга
Кайчак җитә матур сүзләр,
якты караш бит аларга.
Безнең йөрәк бер кайчан да суынмасын
бу тормышта
Күпчелеккә кирәк әле булышырга.
Кичер, дустым, белгәннәрне,
күргәннәрне,
Сиңа булган авыр сүзләр әйткәннәрне;
Шул чагында Ходай бирер
күңелләргә тынычлыкны
Үлгәндә дә Ходай бирер һәммәбезгә
җиңеллекне.

**Хәсибулла Зәйнетдинов,**
**Тукай районының Кече Шилнә авылы.**

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:

**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**19 май 16 сәг.**
**фактта 19 май 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**